РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава
Карамалинского сельского
поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Центральная, д. 8, Азнакаевский район,
с.Карамалы, 423301,
тел./факс (885592)45-6-42
E-mail: Karam.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Карамалы авыл җирлеге
башлыгы

Үзәк ур., 8нче йорт, Азнакай районы,
Карамалы авылы, 423301
тел./факс (885592)45-6-42
E-mail: Karam.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«13» ноябрь 2023 ел** **№ 3**

2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Карамалы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Уставынын 15.1 статьясы нигезендә, карар итәм:

1. Карамалы авылы теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Карамалы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының 2023 елның 23 ноябрендә 14.00 сәгатькә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2024 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, махсус хәрби операциягә җибәрелгән мобилизацияләнгән гаилә әгъзасы булган гаиләләрдән тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 150 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Карамалы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Карамалы авылында урамнарны яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампаларны, энергияне сак тотучы яктырткычларны, электр

товарларын сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуга агымдагы ремонт һәм хезмәт күрсәтү);

- Карамалы авылында юлларны кардан чистарту (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Карамалы авылы  Профсоюз урамында койма ясау, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү, агачларны кисү, куакларны кисү, үлән кисү, чүп-чар җыю, хуҗалык инвентаре сатып алу) ;

- Җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны,  кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Карамалы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм  Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык А.Р. Ногманов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЗНАКАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
КАРАМАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАМАЛИНСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ